СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.10.2025 № 2/13

На №__________ от______________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 22 февралендәге вн/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында кодексы, Тукай муниципаль районы уставы, 2025 елның 22 сентябрендәге 02-08-02-2025/532-25-20920036 номерлы прокуратура протесты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 22 февралендәге вн/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 17 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 17.2.1 пунктын өстәргә:

«17.2.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү турында үтенеч белән гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең 16.1. каралган анкета;

3) паспорт;

4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

5) белем һәм квалификация турында документ;

6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән

очраклардан тыш;

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары – запаста булган гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулый торган авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

10) муниципаль хезмәткә кергән елга кадәрге ел өчен керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;

10.1) әлеге Нигезләмәнең 16 статьясында каралган белешмәләр;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров